РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**Исполнительный комитет муниципального образования «поселок городского типа Актюбинский» Азнакаевского муниципального района**

ул. Губкина, д. 24, п.г.т. Актюбинский,
Азнакаевский муниципальный район,
423304
тел. (факс): (85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты**

Губкин урамы, 24 йорт, Актүбә ш.т.п.,
Азнакай муниципаль районы, 423304
тел. (факс): (85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» гыйнвар 2025 ел № 4

2025 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегенең иң чик күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 23.01.2025 № 33 карары нигезендә «2025 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында», Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлегендә 2025 елның 01 февраленнән күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә 9 165,37 сум (тугыз мең йөз алтмыш биш сум утыз җиде тиен) күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә.

2. «2024 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегенең иң чик күләмен раслау турында» 2024 елның 30 гыйнвар № 6 Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» башкарма комитетының карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 01 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый

мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче И.И. Мөхәмәтҗанов

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» башкарма комитет карарына 1 нче кушымта
«28» гыйнвар 2025 ел № 4

2025 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлектә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясенең чик күләме

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүнең бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1. | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 4 070,37 |
| 2. | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 1 800,00 |
| 3. | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 295,00 |
| | **Барлыгы** | **9 165,37** |

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» башкарма комитет карарына 2 нче кушымта
«28» гыйнвар 2025 ел № 4

2025 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлектә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясенең чик күләме

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүнең бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1. | Кәфенләү | 1 500,00 |
| 2. | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 2 570,37 |
| 3. | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 1 800,00 |
| 4. | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 295,00 |
| | **Барлыгы** | **9 165,37** |